# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **22.11.2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлегенә керүче Мәсгут авылында 2020 елда үзара салым җыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлегендә халык җыены карар бирә:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400,00 (дүрт йөз) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2 группа инвалидлар өчен 200 сум күләмендә түләүне киметергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:

- Мәсгут авылы юлларын вак таш һәм гравий белән төзекләндеру
- Мәсгут авылы зиратын коймалау
- Мәсгут авылында урам исемнәре язылган курсәткечләр ясату
- Бәйрәм чараларын оештыру Һәм уткәру (Яна ел, Җиңу көне, Сабантуй, Халыкара өлкәннәр көне)

3. Әлеге халык җыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәсгут авылы, Дуслык ур., 12 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәсгут авыл җирлеге башлыгы Э.Ә. Габдрахманов